ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 987 04.12.2018

***Постановление*** ***Карар***

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы башкарма комитетының 22.06.2018
елгы 471 нче карары белән расланган
Чистай муниципаль районында
”Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең
(балалар бакчалары) төп гомуми белем
бирү программасын тормышка ашыручы
белем бирү оешмаларына исәпкә
кую һәм кабул итү” буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Чистай шәһәр прокуратурасының 26.11.2018 елгы 02-08-02-2018 нче номерлы протестын үтәү йөзеннән, 27.07.2010 елгы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 22.06.2018 елгы 471 нче карары белән расланган Чистай муниципаль районында ”Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү” буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.1 пунктның 3нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, әлеге Административ регламент белән каралмаган документлар яки мәгълүматлар яисә гамәлләр башкаруны таләп итү»;

1.2. 5.1 пунктны 10 нчы пунктча белән тулыландырырга:

«10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартуда булмаулары һәм (яки) дөрес булмаулары, күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү яисә түбәндәге очраклардан кала муниципаль хезмәт күрсәтү:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында беренче тапкыр гариза биргәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив-хокукый актлар таләпләрен үзгәртү;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, гариза бирүче биргән документларда яисә алдан тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу срогы чыгу яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң мәгълүматны үзгәртү;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда хаталы яки хокукка каршы гамәлләре (эшләмәүләре) турында документаль расланган фактлар (билгеләр) ачыкланса, муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә гариза бирүчегә хәбәр ителә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр».

1.3. 5.8. пунктның 2пунктчасындагы 2 абзац түбәндәге редакциядә бәян ителә:

«5.9. Карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язма формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында сәбәпләр күрсәтелгән җавап җибәрелә.

5.9.1 Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылганда, гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәтүче орган башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, бу муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны тиз арада бетерү максатында эшләнә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт алу максатында нәрсә эшләргә тиешлеге турында мәгълүмат бирелә.

5.9.2 Шикаятьне канәгатьләндерү мөмкин түгел дип табылганда, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә».

1.4. 5.9 пункт түбәндәге редакциядә бәян ителә:

«5.10. Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки вазифаи затның, шикаятьне карау буенча

вәкаләте булган хезмәткәрнең җинаять кылу билгеләре ачыкланса, булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына җибәрәләр».

2.”Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының мәгариф идарәсе” МКУга (О.В. Купцова) әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында: http://chistopol.tatar.ru/, Татарстан Ресрубликасының рәсми хокукый-мәгълүмат интернет-порталында: pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Әлеге карарны үтәүгә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов